ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

11 04 2022 г. № 196

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 1 октябрендәге 842 номерлы карары белән расланган бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урынны торак урыны, торак урыны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә, сүтелергә һәм үзгәртеп төзелергә тиешле, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турында Нигезләмәнең 61 пунктына үзгәреш кертү хакында» 2022 елның 17 февралендәге 187 номерлы карары нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 1 октябрендәге 842 номерлы карары белән расланган бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча му-ниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (3 нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.8.2 пунктының «8-14» пунктчалары номерларын «1-7» пунктчалары дип санарга;

2.8.2 пунктына түбәндәге эчтәлекле пунктча өстәргә:

«8) суга бату, су басу зонасы чикләрендә урнашкан җир кишәрлегендә бакча йортын урнаштыру (бакча йортын торак йорт дип тану турында гаризаны караганда).».

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районы Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Ә. Хаҗиевка йөкләргә.

Җитәкче Р.Х. Муллин

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044881